ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКА-
СЫ АКТАНЫШ МУНИЦИ-
ПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮКЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423732, Түке авылы,
Ленин ур.,61/2 нче йорт.
Тел. 3-44-61

СОВЕТ ТЮКОВСКОГО СЕЛЬ-
СКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙО-
НА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423732, село Тюково,
ул.Ленина, дом 61/2
Тел. 3-44-61

КАРАР

16.09.2026 ел №13

Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәне раслау хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 24 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының « Түке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Түке авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Түке авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга.

2. Түке авыл җирлеге Советы карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

- «Актаныш муниципаль районының Түке авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 28.10.2009 ел, № 17;
- «Актаныш муниципаль районының Түке авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәне раслау хакындагы» карарга үзгәрешләр кертү турында» 19.06.2011ел, №6;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Түке авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Х.М.Загиров

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы Түке
авыл җирлеге Советы 16.09.2026
ел №13 карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында Нигезләмә

Әлеге Нигезләмә Түке авыл җирлеге Советы депутатының (алга таба - депутат) хокукларын һәм бурычларын билгели, үз вәкаләтләрен башкарганда төп хокукый һәм социаль гарантияләрне күздә тота.

**1нче статья. Депутат статусының хокукый нигезе**

1. Депутат статусы Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Түке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Уставы (алга таба — җирлек Уставы) һәм Нигезләмә нигезендә билгеләнә.
2. Депутат булып бермандатлы сайлау округы буенча муниципаль сайлауларда сайланган һәм Түке авыл җирлеге Советында (алга таба – җирлек Советы) Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарында һәм муниципаль норматив хокукый актларда каралган вәкиллекле һәм башка вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга вәкаләтле Россия Федерациясе гражданы тора.
3. Депутат үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, җирлек Уставына һәм муниципаль норматив хокукый актларга, шулай ук сайлаучыларның мәнфәгатьләренә таяна.
4. Депутатка үз вәкаләтләрен тоткарлыксыз башкару өчен шартлар тәэмин ителә.
5. Депутат үз статусын депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле булмаган эшчәнлек өчен кулланырга хокуклы түгел.

**2 нче статья. Депутат эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары**

1. Депутатлар, җирлек Уставында билгеләнгән очраклардан тыш, үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаралар, депутат эшчәнлеген төп эш урыны буенча хезмәт һәм хезмәт бурычларын үтәү белән бергә алып баралар.
2. Депутатка үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыру өчен, эш бирүче тарафыннан эш урынын (вазыйфасын) саклап калып, дәвамлылыгы җирлек Уставы белән билгеләнгән чорга эштән азат ителү гарантияләнә.
3. Җирлек Советының билгеләнгән саныннан депутатларның 10 проценттан артыграгы даими нигездә эшли, ә җирлек Советының саны 10 кешедән кимрәк булса - 1 депутат.

**3 нче статья. Депутат вәкаләтләре срогы**

1. Депутат вәкаләтләре срогы биш елны тәшкил итә.
2. Депутатның вәкаләтләре ул сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш җирлек Советының тулы хокуклы составта беренче утырышын уздырган көннән туктатыла.

**4 нче статья. Депутат статусына бәйле чикләү, тыюлар**

1. Депутатлар Россия Федерациясе сенаторлары, Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутатлары, Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару органнары депутатлары була алмый, Россия Федерациясенең башка дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт вазыйфаларын, шулай ук дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт вазыйфасын биләп тора алмый, моңа «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - 33-ФЗ номерлы Закон), башка федераль законнарда билгеләнгән очраклар керми.

2. Депутат, 33-ФЗ Законы һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш, бер үк вакытта башка муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы депутаты яки башка муниципаль берәмлекнең башлыгы вәкаләтләрен башкара алмый.

3. Депутатлар Россия Федерациясенең коррупциягә каршы көрәш турындагы законнары белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны сакларга, бурычларны үтәргә тиеш.

4. Үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатлар хокуклы түгел:

1) шәхсән яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә катнашудан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш) Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Рәисенә алдан хәбәр итү белән;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;

г) муниципаль берәмлек исеменнән оешманың тулы гамәлгә куючысы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яки муниципаль милектәге акцияләргә (устав капиталындагы өлешләргә)идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль берәмлекнең идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлеге бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән финанслана алмый;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, чит ил коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган оешмаларының һәм Россия Федерациясе территориясендә аларның структур бүлекчәләренең башка органнары составына керергә.

5. Даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар гражданлык, административ яки җинаять эше буенча яки административ хокук бозу турындагы эш буенча яклаучы яки вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан тыш) сыйфатында катнаша алмыйлар.

**5 нче статья. Депутат вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу**

1. Депутат вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) үлем;

2) үз теләге белән отставкага китү;

3) суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылу;

4) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылу яисә вафат дип игълан ителү;

5) аңа карата судның гаепләү карарының законлы көченә керүе;

6) Россия Федерациясеннән читкә даими яшәү урынына чыгу;

7) Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылу яисә чит ил дәүләтенең гражданлыгы булу яки яшәү төре яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукынраслый торган башка документ булу;

8) Җирлек Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

9) хәрби хезмәткә чакыру яисә аны алыштыра торган альтернатив граждан хезмәтенә китү;

10) чит ил агенты статусын алу;

11) 33-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән башка очраклар.

2. Депутатның вәкаләтләре, әгәр ул җирлек Советының барлык утырышларында алты ай рәттән сәбәпсез катнашмаса, җирлек Советы карары белән вакытыннан алда туктатыла.

3. Депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында җирлек Советы тарафыннан карар кабул ителгән депутат, әлеге карарга карата шикаять белдерү турындагы гариза белән әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән алып 10 көн эчендә судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

4. Вәкаләтләре җирлек Советының депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы карары нигезендә вакытыннан алда туктатылган депутат, күрсәтелгән карарга суд тәртибендә шикаять биргән очракта, җирлек Советы суд карары законлы көченә кергәнче җирлек Советы депутатларын өстәмә сайлаулар билгеләү турында карар кабул итәргә хокуклы түгел.

5. Депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы җирлек Советы карары, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә, ә әгәр бу нигез җирлек Советы сессияләре арасында барлыкка килсә, - мондый нигез барлыкка килгән көннән соң өч айдан да соңга калмыйча.

6. Әгәр җирлек Советының депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы карары әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында каралган нигездә әлеге статьяның 5 өлешендә каралган срокларда кабул ителмәгән булса,депутат процессуаль законнарда каралган тәртиптә җирлек Советының гамәл кылмавына шикаять белдерү турындагы гариза белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

7. Татарстан Республикасы Рәисе депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату

өчен нигез барлыкка килгән көн итеп әлеге гаризаның җирлек советына кергән көне санала.

## 6 нчы статья. Депутат хокуклары

1. Депутат түбәндәге хокукларга ия:

1) җирлек Советында даими комиссияләргә һәм тиешле вазыйфаларга сайларга һәм сайланырга;

2) җирлек Советына карау өчен сораулар тәкъдим итәргә;

3) җирлек Советы тарафыннан төзелә торган органнарны һәм җирлек Советы тарафыннан сайлана торган (билгеләп куела торган, килештерелә торган) вазыйфаи затларның кандидатураларын формалаштыру мәсьәләләре буенча үз фикерен әйтергә;

4) хокукый иҗат инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә җирлек Советы хокукый актлар проектларын кертергә;

5) көн тәртибе, тикшерелә торган сорауларның асылы һәм карау тәртибе буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә, җирлек Советы карарлары проектларына төзәтмәләр кертергә;

6) җирлек Советына хисап бирергә тиешле яки контроль астында булган теләсә кайсы органның яки вазыйфаи затның җирлек Советы утырышында чираттан тыш хисабын яки мәгълүматын тыңлау буенча тәкъдимнәр кертергә;

7) җирлек Советы Регламенты белән билгеләнгән тәртиптә фикер алышуда катнашырга;

8) үз тәкъдимнәрен нигезләп һәм тавыш бирү мотивлары буенча чыгыш ясарга, белешмәләр бирергә;

9) җирлек Советы утырышларында, аның фикеренчә, иҗтимагый әһәмияткә ия булган гражданнарның мөрәҗәгатьләрен игълан итәргә;

10) җирлек Советы тарафыннан төзелә торган органнарның составы (сан ягыннан, персональ яктан) һәм җирлек Советы тарафыннан сайлана торган (билгеләп куела торган, килештерелә торган) вазыйфаи затларның кандидатуралары буенча фикер әйтергә;

11) даими комиссияләрнең, җирлек Советы сессияләренең беркетмәләре белән танышырга;

12) депутат ярдәмчеләренә ия булу.

## 7 нче статья. Депутатның таныклыгы һәм күкрәк билгесе

1. Депутат шәхесен һәм Түке авыл җирлеге Советы депутаты вәкаләтләрен раслый торган документ булып торган таныклыкка, шулай ук ул үз вәкаләтләре чоры дәвамында файдалана торган күкрәк билгесенә ия.

## 8 нче статья. Депутат эшчәнлеге формалары

1. Депутат эшчәнлегенең формалары булып тора:

1) җирлек Советы сессияләре эшендә катнашу;

2) җирлек Советының даими комиссиясе эшендә катнашу;

3) федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларына, оештыру-хокукый формаларына, җәмәгать берләшмәләренә җирлек карамагындагы мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итү;

4) муниципаль хокукый акт проектын кертү;

5) җирлек Советы тарафыннан кабул ителә торган муниципаль хокукый актлар

проектларын эшләүдә катнашу;

6) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы тәртибендә җирлек Советы тарафыннан кертелә торган Татарстан Республикасы законнары проектларын эшләүдә катнашу;

7) депутат гарызнамәсе кертү;

8) сайлаучылар белән очрашулар, аларның мөрәҗәгатьләре белән эшләү, үз вәкиле булган җирлек халкына үзләренең эшчәнлеге һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү;

9) җирле референдумнарны, гавами тыңлауларны, җыелышларны, конференцияләрне һәм гражданнардан сорашып белешүләрне оештыруда һәм уздыруда катнашу;

10) территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыруда катнашу.

2. Депутат үз эшчәнлеген федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, башка муниципаль хокукый актлар һәм Түке авыл җирлеге Советы Регламенты белән билгеләнгән башка формаларда да алып барырга мөмкин.

## 9 нчы статья. Депутатның сайлаучылар белән үзара мөнәсәбәте

1. Депутат җирлек халкы, шулай ук җирлек территориясендә урнашкан предприятиеләр, оешмалар, муниципаль һәм башка органнар коллективлары белән элемтәдә тора.

2. Депутат сайлаучылар алдында үз эшләре турында елга бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә хисап тота, аларны җирлек Советы эше турында даими хәбәр итә, шулай ук айга бер тапкырдан да ким булмаган санда халыкны кабул итә.

3. Депутат, законнары белән билгеләнгән чараларны кабул итеп, җирлек халкының законлы хокукларын, ирекләрен һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итә, алардан килгән тәкъдимнәрне, гаризаларны, шикаятьләрне карый, үз вәкаләтләре чикләрендә аларда булган сорауларны дөрес һәм вакытында хәл итәргә ярдәм итә.

4. Гражданнарны кабул итә;

5. Җәмәгать фикерен өйрәнә һәм кирәк булганда тиешле дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм җәмәгать берләшмәләренә тәкъдимнәр кертә.

6. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары Актаныш муниципаль районының Түке авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан сайлаучылар белән очрашулар үткәрү өчен махсус билгеләнгән урыннарда, шулай ук депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен Актаныш муниципаль районының Түке авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан бирелә торган биналарда аларны бирү тәртибенә туры китереп үткәрелә.

7. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә үткәрелә.

8. Депутатның сайлаучылар белән очрашуларын оештыруга яисә уздыруга каршылык күрсәтү Россия Федерациясе законнары нигезендә административ җаваплылыкка китерә.

## 10 нчы статья. Депутатларның депутат этикасы кагыйдәләрен саклау

1. Депутат җирлек Советы тарафыннан расланган депутат этикасы кагыйдәләрен сакларга тиеш, шул исәптән түбәндәге бурычларны үтәргә:

1) үзе яки аның якын туганнарына кагылышлы мәсьәләләрне хәл иткәндә,

җирле үзидарә органнары, оешмалар, вазыйфаи затлар, муниципаль хезмәткәрләр һәм гражданнар эшчәнлегенә йогынты ясау өчен депутат статусын файдаланмау һәм җирле үзидарә органнары эшендә катнашудан тыелу;

2) депутат вазыйфаларын объектив үтәүдә шик тудырырлык үз-үзеңне тотудан тыелырга, шулай ук аның абруена яисә җирлек Советы абруена зыян китерерлек низаглы хәлләрдән качарга;

3) мәнфәгатьләр конфликты килеп чыгу куркынычы булганда - шәхси кызыксыну (турыдан-туры яки читләтеп) депутат вазыйфаларын тиешенчә, объектив, гадел үтәүгә йогынты ясый яки йогынты ясый ала торган вәзгыять булганда;

- бу хакта җирлек советына хәбәр итәргә һәм аның әлеге мәнфәгатьләр конфликтын булдырмауга яисә җайга салуга юнәлдерелгән карарын үтәргә;

4) җирлек Советында билгеләнгән гавами чыгышлар кагыйдәләрен үтәү;

5) депутат эшчәнлегенә бәйле булмаган максатларда конфиденциаль характердагы белешмәләргә кертелгән, депутат бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә аңа мәгълүм булган белешмәләрне ачмау һәм файдаланмау;

6) физик һәм юридик затлардан депутат бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләкләүләр (бүләкләр, акчалата бүләкләү, ссуда, хезмәт күрсәтүләр, күңел ачу, ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү һәм башка бүләкләүләр) алмау.

**11 нче статья. Депутатның җирлек Советы сессияләрендә катнашуы**

1. Депутат җирлек Советының барлык сессияләрендә шәхсән катнашырга тиеш.

2. Депутатка җирлек Советы сессияләрен уздыру вакыты һәм урыны, карауга кертелә торган мәсьәләләр турында хәбәр ителә, шулай ук әлеге мәсьәләләр буенча җирлек Советы регламенты нигезендә барлык кирәкле материалларны ала.

3. Җирлек Советы сессияләрендә катнаша алмаганда, депутат, бер көннән дә соңга калмыйча, бу хакта җирлек Советы Президиумына хәбәр итә.

**12 нче статья. Депутатларның җирлек Советының даими комиссияләре эшендә катнашуы**

1. Депутат әгъза булган җирлек Советының даими комиссияләренең барлык утырышларына шәхсән катнашырга тиеш.

2. Депутатка даими комиссияләр утырышларын уздыру вакыты һәм урыны, карауга кертелә торган мәсьәләләр турында хәбәр ителә, шулай ук әлеге мәсьәләләр буенча җирлек Советы регламенты нигезендә барлык кирәкле материалларны ала.

3. Даими комиссияләр утырышларында катнаша алмаганда, депутат, бер көннән дә соңга калмыйча, бу хакта даими комиссия рәисенә яисә җирлек Советы аппаратына хәбәр итә.

**13 статья. Депутатның вазыйфаи затлар тарафыннан беренче чиратта кабул итүгә хокукы**

1. Депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча депутат Түке авыл җирлеге (алга таба – җирлек) җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр җитәкчеләре тарафыннан чираттан тыш кабул итү хокукыннан файдалана.

2. Депутат вазыйфаи затка турыдан-туры яисә вазыйфаи затның кабул итү бүлмәсе (секретариаты) аша телдән яки язмача мөрәҗәгать итә.

3. Телдән мөрәҗәгать иткән очракта кабул итү вакыты җирлек Советы депутаты белән килешенгән вазыйфаи зат тарафыннан билгеләнә, ә депутат язмача

мөрәҗәгать иткән очракта кабул итү вакыты депутат мөрәҗәгатен алган көннән өч көннән дә соңга калмыйча вазыйфаи зат тарафыннан билгеләнә.

4. Депутатны өч көн эчендә кабул итә алмаганда, депутат белән килешү буенча вазыйфаи зат башка вакытны билгели.

## 14 нче статья. Депутатның мәгълүмат алу һәм тарату хокукы

1. Депутат үз депутатлык эшчәнлегенә бәйле мәсьәләләр буенча, закон белән яшерен саклауны таләп итмәгән мәгълүматны җирле үзидарә органнарыннан, муниципаль предприятиеләрдән, учреждениеләрдән һәм аларның вазыйфале затларыннан алу хокукына ия.

2. Депутат үз эшчәнлеге мәсьәләләре буенча федераль законда күздә тотылган тәртиптә массакүләм мәгълүмат чараларында чыгыш ясарга хокуклы.

## 15 нче статья. Депутат мөрәҗәгатьләрен карау

1. Депутат дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, барлык оештыру-хокукый рәвешләрдәге оешмаларга, иҗтимагый берләшмәләргә, депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча тиешле вазыйфаи затларга телдән яисә язмача мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2. Җирле үзидарә органнары, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр һәм аларның вазыйфале затлары, депутат депутатлык эшчәнлеге мәсьәләләре буенча мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгатьне алган көннән башлап 15 көн эчендә, әгәр ул өстәмә тикшерү яки тикшерү таләп итмәсә, депутатка аның мөрәҗәгатенә җавап бирергә яки ул сораган документларны яки мәгълүматны бирергә тиеш.

3. Депутат мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә нинди дә булса сорауларны өстәмә тикшерү яисә өстәмә өйрәнү үткәрергә кирәк булган очракта, әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән вазыйфаи затлар һәм җитәкчеләр бу хакта депутат мөрәҗәгатен алган көннән алып 15 көн эчендә депутатка хәбәр итәргә тиеш. Соңгы җавап депутатка депутатның язма мөрәҗәгатен алган көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

4. Депутатларның дәүләт органнарына, аларның оештыру-хокукый формасыннан бәйсез оешмаларга җәмәгать берләшмәләренә, аларның вазыйфаи затларына мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе һәм вакытлары законнар белән билгеләнә.

5. Депутат үзенең мөрәҗәгатендә куйган мәсьәләләрне җирле үзидарә органнары, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан карауда турыдан-туры катнашу хокукына ия.

## 16 нчы статья. Депутат соравы

1. Депутат яисә депутатлар төркеме җирлек Советы компетенциясенә керә торган мәсьәләләр һәм үзенең депутатлык эшчәнлеге мәсьәләләре буенча җирлек башлыгына, җирле үзидарә органнары, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр җитәкчеләренә депутат гарызнамәсе белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2. Депутат гарызнамәсе җирлек Советы сессиясендә язма рәвештә кертелә һәм җирлек Советы сессиясендә игълан ителә. Депутат гарызнамәсен рәсмиләштерү җирлек Советы Регламенты нигезендә башкарыла.

3. Депутат гарызнамәсе җибәрелгән Орган яисә вазыйфаи зат аңа җавапны алган көннән алып 15 көн эчендә язма рәвештә бирә.

## 17 нче статья. Депутатның бурычлары

1. Депутат түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) үз эшчәнлеген алып барганда РФ Конституциясен, федераль законнарны, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы законнарын, җирлек Уставын, башка муниципаль хокукый актларны сакларга; гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклауны һәм яклауны тәэмин итәргә;

2) сайлаучыларны даими рәвештә, кимендә айга бер тапкыр кабул итәргә;

3) гражданнарның, барлык оештыру-хокукый рәвешләрдәге оешмаларның, иҗтимагый берләшмәләрнең, дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының мөрәҗәгатьләрен үз вакытында карарга һәм аларга үз компетенциясе чикләрендә җаваплар бирергә;

4) сайлаучылар алдында очрашуларда хисап тотарга, шулай ук үз эшләре турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша елга кимендә бер мәртәбә хәбәр итәргә;

5) депутат вәкаләтләрен үтәү белән бәйле чикләүләрне сакларга;

6) дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне сакларга, шулай ук депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә гражданнарның шәхси тормышына, намусына һәм абруена кагылышлы аңа билгеле булган мәгълүматларны ачмаска.

2. Депутат федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, җирлек Уставы һәм җирлек Советының муниципаль хокукый актлары белән үзенә йөкләнгән башка бурычларны башкара.

## 18 нче статья. Депутатның җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары белән үзара мөнәсәбәте

1. Депутат, җирле үзидарәнең коллегиаль органы әгъзасы буларак, җирлек Советының, аның органнарының эшчәнлегендә актив катнашуны тәэмин итүче барлык тулы хокукларга да ия.

2. Җирлек советы депутатның сайлау округындагы, җирлек Советындагы эше, җирлек Советы карарларын һәм йөкләмәләрен үтәве турында хәбәрен тыңлый.

3. Җирле үзидарә органнары һәм вазыйфалы затлары депутатка аның эшендә кирәкле ярдәм күрсәтәләр, депутатка җирле үзидарә органнары эшчәнлеге, икътисадый һәм социаль үсеш программаларын үтәү барышы, депутат тәкъдимнәре һәм критик кисәтүләр буенча кабул ителгән чаралар турында хәбәр итәләр, депутат тарафыннан законнарны, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары эше практикасын, җәмәгатьчелек фикерен өйрәнүгә ярдәм итәләр.

## 19 нчы статья. Депутат эшчәнлегенә социаль һәм башка гарантияләр

1. Депутат эшчәнлеген гамәлгә ашыруның социаль һәм башка гарантияләре җирлекнең законнары, муниципаль норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

2. Депутатларны җинаять яисә административ җаваплылыкка тартканда, тоткарлаганда, кулга алганда, тентүдә, сорау алуда, аларга карата башка җинаять-процессуаль һәм административ-процессуаль гамәлләр кылганда, шулай ук депутатларга карата, алар биләгән торак һәм (яисә) хезмәт урыны, аларның багажы, шәхси һәм хезмәт транспорт чаралары, язышу вакытында оператив-эзләү чаралары уздырганда депутатларның хокуклары гарантияләре алар файдалана торган элемтә чаралары, аларга караган документлар федераль законнар белән билгеләнә.

3. Депутат әйтелгән фикер, тавыш биргәндә белдерелгән позиция һәм депутат статусына туры килә торган башка гамәлләр өчен, шул исәптән вәкаләтләр чоры

тәмамлангач та, җинаять яисә административ җаваплылыкка тартыла алмый. Әлеге Нигезләмә депутат тарафыннан федераль законда каралган гавами мыскыллаулар, яла ягулар яисә башка хокук бозулар җибәрелгән очракларга кагылмый.

4. Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары нигезендә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән өчен депутатның коллегиаль карарлар кабул итүдә (шул исәптән көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча тавыш бирүдә) катнашуы яки билгән вазыйфасы буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган башка бурычларны үтәве депутатны җаваплылыкка тарту өчен нигез булып тормый.

## 20 нче статья. Депутат эшчәнлеген гамәлгә ашыруда каршылыклар тудырган өчен җаваплылык

Җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм иҗтимагый берләшмәләрнең вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезләмәләрен үтәмәү, шул исәптән әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән срокларны һәм депутат гарызнамәләренә һәм мөрәҗәгатьләренә җаваплар бирү тәртибен үтәмәү, белә торып ялган мәгълүмат бирү, мәгълүмат бирүдән хокуксыз баш тарту, аны бирүдән читләшү, депутатларны кабул итү кагыйдәләрен бозу, законнарда каралган җаваплылыкка китерә.